СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.09.2024 Баулы шәһәре № 268

Баулы муниципаль район Советының
2021 елның 14 декабрендәге 92 номерлы
«Баулы муниципаль районы территориясендә
муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру хакында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль законына ярашлы, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 14 декабрендәге 92 номерлы «Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру хакында» карарына (Баулы муниципаль район Советының 2022 елның 11 апрелендәге 111 номерлы, 2023 елның 20 июнендәге 188 номерлы, 2023 елның 26 октябрендәге 223 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәсендә:

60 пунктның беренче абзацында «66 статьяның 12 өлеше» сүзләрен «66 статьяның 12 һәм 12.1 өлешләре белән» сүзләре белән алмаштырырга;

62 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урынга барып тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча, 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров